Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең
Елховой торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

19 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 19 ноябре 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 19 ноябре 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 19 ноябре 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә "«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтү өчен түләү, күперләрне ремонтлау өчен материаллар сатып алу, чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу?" сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 560 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 331 кеше, бу 59 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 331-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтү өчен түләү, күперләрне ремонтлау өчен материаллар сатып алу, чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Елховой авылы, Совет урамы, 67 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.А.Хәсәншин

ЕЛХОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
Р.05-11259/12
ИНН 1607002096
КПП 164401001